СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

29 гыйнвар, 1997ел.
ЧӘРШӘМБЕ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. № 10 (8022) Бәясе билгеләнгәнчә

## КҮЗ ТОТАРДАЙ МАЯКЛАРЫБЫЗ БАР

### 25 гыйнварда районда авыл хуҗалыгы һәм эшкәртү промышленносте алдынгылары слеты булды

Бу традицион вакыйгага, мөгаен бөтен Норлат әзерләнгәндер. Шәһәрнең үзәк мәйданында тезелеп киткән мул сәүдә рәтләре дә, район мәдәният йорты эчендә үзебездә җитештерелгән нигъмәтләр белән бәйрәмчә бизәлгән өстәлләр дә, купшыланып киткән тамаша залы да - һәммәсе авыл хезмәтчәннәренең очрашуына үзенчә бер күтәренкелек рухы бирде. Ә сәхнә алдына шушы көнгә махсус итеп пешерелгән төрле зурлыктагы түгәрәк ипиләр һәм 40 литрлы бидоннан алып йодырык кадәрле генә кувшинга кадәр сөт савытлары тезелеп киткән - крестьян һәм фермер хуҗалыклары ассоциацияләренең былтыр ашлык һәм сөт җитештерүгә керткән өлешләрен күрсәтүнең әнә шундый бик гыйбрәтле юлын тапканнар. Быелгы слетның тагын бер үзенчәлеге аңа хөрмәтле кунаклар итеп дистә елларча гомерләрен җиргә хезмәт итүгә багышлаган һәм хезмәтләре белән заманында районыбызның республикада озак еллар иң алдынгылар сафында баруына булышлык иткән ветераннарның да чакырылуы иде.

Очрашуны район хакимияте башлыгы Ф.С.Сибагатуллин ачты. Слетта катнашучылар районыбыз биографиясенең иң якты һәм нәтиҗәле өлеше аның исеме белән бәйле булган Социалистик Хезмәт Герое Г.К.Гыйматдиновны минутлык тынлык белән искә алдылар.

Узган хуҗалык елында ирешелгән нәтиҗәләр белән слетта доклад ясаган авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек идарәсе начальнигы Ә.Н. Рәхмәтуллин таныштырды.

**(Ахыры 2 нче биттә).**





**Рәсемнәрдә: Икмәк - иң олы бүләк; былтыргы урак батырлары Рәшит Насыйбуллин, Александр Донсков һәм Владимир Никитин.**

## ЧЫН ХУҖАЛАРЧА ЭШЛИК!

### Авыл хуҗалыгы производствосы алдынгылары слетында катнашучыларның агропромышленность комплексының барлык хезмәтчәннәренә Мөрәҗәгате

Хөрмәтле иптәшләр! Кадерле авыл хуҗалыгы хезмәтчәннәре!

Без, авыл хуҗалыгы производствосы алдынгыларының район слетында катнашучылар, агропромышленность комплексының барлык хезмәткәрләрен ит, сөт, икмәк, азык һәм техник культуралар җитештерүне күтәрү, 1997 нче елда бөртеклеләрнең һәр гектарыннан ким дигәндә 30 центнер, шикәр чөгендереннән 250 центнер уңыш җыю, һәр баш шартлы терлеккә 36 центнер азык бирәмлеге күләмендә терлек азыгы хәзерләү өчен бөтен көчләрен куярга һәм тәҗрибәләрен тупларга чакырабыз.

Дәүләткә 50.000 тонна ашлык сатарга, югары җилемсәле каты бодай игүгә аеруча зур игътибар бирергә һәм аны кимендә 30.000 тонна сатарга, кыйммәтле мал азыгы буларак кукуруз җитештерүне ары таба да үстерергә кирәк. Моның өчен авылның һәр эшчәненең үзен үз җире хуҗасы итеп тоюына ирешелергә тиеш. Җир реформасы һәр коллективның бурычы булып торсын. Крестьян хуҗалыклары ассоциацияләрендә хуҗалык исәпле звенолар, бодай, бөртек өчен кукуруз, шикәр чөгендере, азык культуралары игү буенча кооперативлар оештырырга кирәк.

Авыл халкының шәхси хуҗалыкларын үстерү дә зарури. Бәрәңге, суган, яшелчә, җиләк - җимеш игелә торган мәйданнарны киңәйтергә, сыер, дуңгыз, кош - кортның баш санын арттырырга - товар продукциясе җитештерү нигезендә авыл гаиләсенең керемен арттырырга.

Хәзерләүләр оешмаларын халыктан 30.000 центнер сөт, 1000 центнер ит, бәрәңге, суган, яшелчә сатып алып хәзерләүне тәэмин итәргә, саткан продукция өчен исәп - хисапны да үзвакытында ясап барырга чакырабыз.

Терлекчелек продукциясе белән тәэмин итү бурычларын хәл итү күп очракта нәсел, продуктлылык сыйфатына, көтүне яңарту буенча планлы эшкә бәйле. Һәр сыердан савымны 3.200 килограммга, мөгезле эре терлекләрнең тәүлеклек артымын 650 граммга, дуңгызларныкын 350 граммга, шул исәптән симертүдәгеләренекен 500 граммга җиткерергә, 100 баш сыердан 95 бозау алып, аларның 100 процент сакланышын тәэмин итәргә. Дәүләткә 28 мең центнер сөт, 26 мең центнер ит сатарга.

Районның барлык хуҗалыкларында дуңгызчылыкны үстерергә, быелның июнь аена 40 мең баш дуңгыз баласы алырга һәм дуңгызчылык комплексына һәр циклга 10ар мең баш дуңгызны симертүгә куярга. Терлекчелекнең барлык тармакларында чыгымнарга каршы механизм кулланырга. Производство эшчәнлегенең ахыргы максаты экономик нәтиҗә булып торырга тиеш. Һәр җирдә чыгымнарны киметү, үзкыйммәтне төшерү, продукциянең реализация бәясен күтәрү буенча көрәшергә кирәк. Эшләүче һәр кешегә продукция реализацияләүне 20 миллион сумга кадәр җиткерергә кирәк.

Без, бүгенге слетта катнашучылар, районның авыл хуҗалыгы производствосының барлык хезмәткәрләрен иҗади, һәр эш урынында көч һәм энергияне куеп эшләргә, 1997 елгы программаны уңышлы үтәү өчен бөтен тырышлык һәм осталыкларын җигәргә чакырабыз.

Үз алдыбызга куелган бурычыбызның намус белән үтәләчәгенә шигебез юк.

## Безнең хакта уңай фикерләр генә

Узган атнада Казанда район, шәһәр һәм күп тиражлы газеталар һәм башка массакүләм матбугат чаралары редакторлары өчен семинар үткәрелде.

Журналистлар алдында Татарстан Республикасы халык депутатлары, министрлыклар җитәкчеләре, КДУ галимнәре чыгыш ясады.

Семинарның йомгаклау көнендә Татарстан Фәннәр академиясе бинасында республиканың барлык төр газета һәм журнал баш редакторлары, нәшрият директорлары белән Премьер - министр Фәрит Мөхәммәтшин очрашты. Фәрит Хәйруллович 1996 елда республикабызның социаль - икътисадый тормышы һәм 1997 нче елга билгеләнгән бурычлар турында дәлилле сөйләде, матбугат хезмәткәрләренең сорауларына җавап бирде.

Очрашуда Премьер - министр урынбасары И.К.Хәйруллин, мәгълүмат һәм матбугат министры И.Г.Әхмәтҗанов катнашты.

Соңыннан үткән киңәйтелгән коллегиядә Татарстанда икетеллелекне гамәлгә ашыру, газета нәшер итүгә кагылышлы башка байтак мәсьәләләр турында да сөйләшү булды. Иң куанычлысы шул, анда безнең «Дуслык» район газетасы адресына уңай фикерләр генә яңгырады. Узган ел газетаны компьютерлар ярдәмендә җыю һәм версткалый башлавыбыз, шулай итеп, аның полиграфик башкарылуының, сыйфатының күтәрелүе, соңгы вакытта газета битләрендә урын алган язмаларның тематикасы киңәю һәм башкалар аерым билгеләп үтелде. Быелның беренче яртысында тиражларын арттырган газеталар исемлегендә дә безнең «Дуслык» беренчеләр исәбендә аталды.

## Лондонда фотоальбом

Лондонда Татарстан Президенты Минтимер Шәрип улы Шәймиевның эш һәм тормыш мизгелләрен сурәтләгән фотоальбом басылып чыкты. Анда урнаштырылган фотосурәтләрдә бөтен халык тарафыннан сайланган беренче Илбашыбызның якты образы төрле яклап һәм тулы ачыла.

Әлеге фотоларның байтагы белән 25 гыйнвардан башлап «Идел» күргәзмәсендә танышырга мөмкин.

## «Эфир» татарча сөйли

Башкалабыз Казанда берничә ел элек ачылган «Эфир»телеканалының үз тапшыруларын гел рус телендә генә алып баруы күп милләттәшләребезнең эчен пошырып килгән иде. Ниһаять, халыкның урынлы таләбенә колак салырга мәҗбүр булдылар. 20 гыйнварда - Татарстан Президенты Минтимир Шәймиевкә 60 яшь тулган көндә «Эфир» каналы аша «Адымнар» исемле беренче татарча тапшыруга, эфир аша чыгыш ясап, Президент М.Ш.Шәймиев, Татарстан халык депутатлары Т.Миңнуллин һәм Ф.Сафиуллин уңышлар теләделәр.

Татарча «Адымнар» тапшыруы эфирга һәр атнаның дүшәмбе көнендә - кичке 7 туларга 20 минут кала чыгачак.

## «ТУ»лар очар кебек

Россия Федерациясе хөкүмәте 1997 елда авиакомпанияләргә 38 яңа самолет алу мөмкинлеге булачагын белдерде. Әлеге сүз чынга аша калса, Казан авиатөзәтүчеләренә дә ел буена эш җитәрлек булачак дигән сүз. Чөнки сатып алынырга тиешле 38 самолетның 8е - безнең «ТУ».

## Коръән укучылар ярыша

3 - 4 февральдә «Әл - Мәрҗани» җәмигъ мәчетендә «Ибраһим әл - ибраһим» Россия фонды һәм Казан мөхтәсибәт идарәсе көче белән Корънне оста итеп укучылар конкурсы уздырыла. Ярышта 25 яшьтән узмаган барлык Коръән - Хафизлар да катнаша ала. Җиңүчеләрне кыйммәтле бүләкләр көтә. Әлбәттә, аның иң кадерлесе - апрель аенда Мәккәгә хаҗ сәфәренә чыгу өчен юллама.

## Котлыйбыз!

Яшьләргә белем һәм тәрбия өлкәсендәге казанышлары өчен Октябрь районы, Норлат шәһәренең 3 нче гомуми урта белем бирү мәктәбе биология укытучысы **ШАРТЫНОВА Юлия Павловнага** ***«Татарстан Республикасының атказанган укытучысы»*** дигән мактаулы исем бирелде.

## Мәчет ачылу тантанасына чакырабыз

Хөрмәтле райондашлар, кадерле якташлар!

1997 елның 3 февралендә Төрнәстә авыл тарихында беренче мәчетне тантаналы төстә ачу була. Районыбызның хак мөселманнарын, авылдашларыбызны һәм теләге булган барча кешене безнең бу шатлыгыбызны уртаклашырга килергә чакырабыз.

Мәчет ачу тантанасы иртәнге сәгать 10да башлана.

# КҮЗ ТОТАРДАЙ МАЯКЛАРЫБЫЗ БАР

**(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)**

Ул игенчелектә аз чыгымнар сораучы һәм энергияне сакларга мөмкинлек бирүче технологияләр нигезендә җирнең уңдырышлылыгын һәм кырларның уңыш бирүчәнлеген күтәрү төп бурыч булып калуын, кукурузны, рапсны, кандала үләнен, шикәр чөгендерен орлыкка үстерү тәҗрибәсен киңрәк куллану, органик һәм минераль ашламалар белән рациональ эш итү зарурлыгын билгеләп үтте. Терлекчелектә дә файдаланылмаган резервлар бар. Бу тармакта малларның баш саны азаюга, продуктлылыгы төшүгә һәм продукция әзерләү күләмнәре кимүгә һич юл куярга ярамый, нәсел һәм көтүне яңарту эшен дә планлы төстә алып барырга кирәк.

Ә барлык бу мәсьәләләрдә безгә тигезләнер өчен маяклар бар. Проблемаларыбыз никадәр генә күп булса да, безнең бу җирләрдә менә дигән уңыш үстерергә, югары савымга ирешергә дә, алдынгы технологияләрне белеп һәм нәтиҗәле кулланырга да мөмкинлекләребез бар.

Былтыр төрле тармакларда һәм эш участокларында алгы урыннарга чыккан хуҗалыклар, бригадалар, звенолар, комбайнчылар, шоферлар, эшкәртү предприятиеләре эшчеләре, чөгендерчеләр, ферма коллективлары һәм терлекчеләрне зурлап бүләкләгәндә залдагы һәркем үзенең эш нәтиҗәләрен аларныкы белән чагыштыргандыр. Алдынгыларның да алдынгылары бу көнне мактау кәгазьләренә, истәлек тасмаларына һәм кыйммәтле бүләкләргә ия булдылар, алар адресына бик күп җылы сүзләр, матур теләкләр, татар, рус һәм чуваш телләрендә җырлар яңгырады. Ни әйтсәң дә гомуми нәтиҗәләр бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр тырышып хезмәт итүче шушы фидакарьләр эшеннән җыела бит.

Слетта йомгаклау сүзе белән Ф.С.Сибагатуллин чыкты. Алдан әзерләнгән тезисларын читкә куеп, ул очрашуда катнашучылар белән эчкерсез сөйләшүгә күчте. Хуҗалык итә белүнең иҗтимагый җитештерүнең барлык тармакларында да икътисадый нәтиҗәлелекнең күтәрелүе белән бәяләнүен ассызыклап һәм әйткәннәрен аерым звенолар һәм хуҗалыклар мисалында конкрет саннар белән ныгытып Фатыйх Сәүбәнович:

- Хәзер читтән кем дә булса килеп ярдәм итүен көтеп тора торган вакыт түгел,- диде. - Без бүген үз алдыбызга куйган ахыр нәтиҗәгә йөз тотып эш итәргә тиешбез. Һәркемнән нәтиҗәле хезмәт, эшкә хуҗаларча мөнәсәбәт, саный - исәпли белү сорала. Яхшырак эшлибез икән - кешечәрәк яши башлаячакбыз. Октябрь районы үзенең эш күрсәткечләре буенча республикада яңадан яхшылар сафына кайтырга тиеш. Моның өчен бездә тиешле җитештерү һәм кадрлар потенциалы бар.

Слетта катнашучылар районның барлык агропромышленность комплексы хезмәтчәннәренә иҗади, энергия белән һәм бар көчне куеп эшләргә чакырган Мөрәҗәгать белән чыктылар.

***

Слетта сүз алып, «Норлат шикәр заводы» акционерлар җәмгыяте генераль директоры А.К.Савинов АҖ сайлаучыларының 50 нче Октябрь административ - территориаль сайлау округыннан Татарстан Республикасы халык депутатлыгына кандидат итеп бертавыштан район хакимияте башлыгы Ф.С.Сибагатуллинны күрсәтүләре турында хәбәр итте. Залдагыларгның бу хәбәрне алкышлап кабул итүе район башлыгының республика парламентында лаеклы вәкилебез булачачына ышануларын раслаулары да иде.

***

... Традицион еллык очрашу тәмам. Менә иң яхшы хуҗалыкларның уңган эшчәннәре һәм белгечләре, промышленность предприятиеләре алдынгылары, район җитәкчеләре белән бергәләп истәлеккә рәсемгә дә төштеләр. Алга таба эштә дә шулай күмәк булырга язсын. Соңыннан авыл эшчәннәре шәһәр предприятие һәм оешмаларында кунак булып, бу бәйрәмнән якты хатирәләр белән таралышты. Алда аларны тагын көндәлек хезмәт, эш һәм йорт мәшәкатьләре көтә. Аларга моннан ары да түземлелек һәм сабырлык юлдаш булсын, хезмәтләренең нәтиҗәсен күреп куанырга язсын.

**Т.НАЗАРОВА.**







**Рәсемнәрдә: Муса Җәлилләләр былтыр мал азыгын иң күп әзерләүчеләрдән булды; слетның иң матур мизгелләреннән берсе анда катнашучыларны балалар котлавы булды, алар район башлыгы белән истәлеккә рәсемгә дә төштеләр; слетта кондырчалылар аеруча еш һәм бары тик уңай яктан гына телгә алынды.**

**Н.АЗИЗОВ фотолары.**

# УРАМ ИСЕМНӘРЕНДӘ - НОРЛАТЫБЫЗ ТАРИХЫ

**Шәһәребез урамнары. Ничә алар, исемнәре ничек һәм аларның тарихы нинди? Менә шул хакта сөйлисе килә бүген.**

Норлат станциясенә (1961 елдан Норлат шәһәре) 1909 елда нигез салынган. Ул елда вокзалның агач бинасы белән тимер юл буена тезелеп киткән берничә йорт кына була әле. 1924 елда Зирекле авылыннан берничә гаилә хәзерге аптека тирәсенә күчеп утырып «Труд» («Хезмәт») поселогын оештыралар.

1929 елда Егоркино волостеның үзәге Норлатка күчерелә, иске типография урынында волость башкарма комитеты бинасы салына. Табигый ки, ул чакта бернинди урам да булмый әле.

1930 елда үзәге Норлат станциясе булган Октябрь районы оештырыла. Шуңа бәйле рәвештә административ һәм торак биналар салына башлый. Әле ул чакта да анык чалымланган урамнар булмый, кайда иркенрәк, шунда йорт салалар. Шуңа күрә халык телендә исполком ишегалды, элеватор ишегалды,МТС, тулай торак, банк ишегалды дигән «адреслар» гына йөри.

1931 - 32 нче елларда төзелеш планлы төстә алып барыла башлый һәм урамнар системасы формалашырга тотына. 1932 елда хәзер НГДУ конторасы урнашкан урында райбашкарманың ике катлы агач бинасы, райком бинасы (хәзер Пионерлар йорты) салына һәм Советская урамы барлыкка килә. Дәүләт банкы, янгын депосы урнашкан перпендикуляр урамга К.Маркс исеме бирелә. Райпотребсоюз һәм кибетләр урамы Кооперативная, мәктәпнеке Школьная дип атала, Спортивная урамы да барлыкка килә.

Архивтагы язуларга караганда, Норлатта Элеватор урамы да булганга охшый (сүз хәзерге Октябрьская урамы турында баргандыр). Бер документта «Хезмәт» поселогы, Стандартная урамы» дигән язу очрый. Сүз хәзерге Пушкин урамы турында баргандыр. Ә менә Пролетарская урамы кайда булды икән? Өлкәннәр хәтерли торгандыр бәлки. Хәзерге Линейная урамы элек Тимер юл урамы дип йөртелгән.

Тимер юл вокзалы артында 30 нчы еллар башында тимер юлчылар өчен икешәр катлы ике һәм өч катлы бер йорттан Куйбышев урамы оеша башлый. Кондырчага таба үз йортын беренче Гусаров салып чыга һәм шуннан Каганович урамы башлана (соңыннан ул 40 лет Октября дип үзгәртелә). Балакирев һәм Нечаев, Киров һәм Фрунзе урамнарына нигез салалар.

Эшчеләр поселогы сугыштан соң шактый киңәя. Биредә шәхси йортлар да күп салына, шул рәвешле яңа урамнар да барлыкка килә: көньякка таба Калинин, Димитров, Южная һ.б., көнбатышка - Мир, Дружба, Победа, Космонавтлар һ.б., көнчыгышка (чоңгылга) таба Комсомольская,Горький, Островский, Садовая,Овражная һ.б., төньякка - Ломоносов, Муса Җәлил, Ленинград һ.б. урамнар тезелеп китә.

Урамнарның зур бер төркеме Норлатта шикәр заводы төзелү һәм разведка бораулавы конторасы ачылу белән бәйле.

Төрле чорларда урамнарның исемнәре алыштырыла. Шоссейная - Синдряков, Мирная - Козлов, Красная - Кузнецов, Каганович - 40 лет Октября, Жданов - Вахитов урамнары дип үзгәртелә, Сенная хәзерге Куйбышев, Свердлов - Советская урамнарының дәвамы булып китәләр.

1997 елның 1 гыйнварена Норлатта 85 урам һәм 8 тыкрык исәпләнә. Шәһәрнең мәйданы 1500 гектар, халкы 27398 кеше.

Шәһәрдә оешып килгән яңа урамнарга исем бирү мәсьәләсенә килгәндә, «Дуслык»ның быелгы 17 гыйнвар санындагы язмага өстәп шуны әйтәсе килә: урамнарга татар халкының тарихи шәхесләре Кол Гали, Коләхмәтов, Кариев, Ватан сугышы геройлары - маршаллар Жуков, Рокоссовский, Конев, рәссамнар, композиторлар, галимнәр Чайковский, Репин, Васнецов, Шишкин, Арбузов, Менделеев исемнәрен биреп була.

Герой шәһәрләр Волгоград, Севастополь урамнарын булдырырга да ярый (Ленинград, Киев урамнары бар бит). Сүз уңаеннан әйткәндә, Московская урамыбыз бар, ә Казан дигәне юк. Аннары, К.Маркс проспектын Татарстан проспекты дип атарга кирәк түгел микән?

Шунысын да әйтик, архив документларына караганда элек урам исемнәрен рәсми төстә раслау булмаган, соңгы елларда гына бу эштә тәртип урнаштырылды һәм ул алга таба да сакланыр дип ышанасы килә.

**И.САНДЛЕР.**

## Мәдәният

# Талантлар эзлибез

**Район мәдәният бүлеге районда үзешчән авторлар һәм башкаручылар конкурсы игълан иткән иде. Мәдәният бүлеге мөдире О.ҖИҺАНШИНАДАН конкурсның барышы һәм максатлары турында таныштырып китүен үтендек.**

- Районның үзешчән авторлары һәм башкаручылары конкурсын игълан иткәндә, без нигездә җыр жанрын - авторлар җыры һәм аны башкаручыларны күздә тотып, яңа, районга әлегә таныш булмаган җырларны, башкаручыларны ачып, киләчәктә концертларда күрсәтүне максат иткән идек. Гаҗәпләнүебезгә каршы, районда шигърият, рәсем сәнгате белән шөгыльләнүчеләрнең дә бихисап булуы ачыкланды. Килүчеләр арасында өч милләт вәкилләре, әдәбият, сәнгатькә гашыйк бөтен яшьтәге кешеләр бар иде, алар үзләренең иҗат җимешләре белән таныштырдылар. Тик шунысын әйтергә кирәк, конкурс турында әллә белмәгәнгә, әллә һава шартлары сәбәпче булганга микән, кайбер авыллардан талантлар үзләрен күрсәтергә килә алмадылар. Шулай да борчылырга урын юк: **конкурс 1 февральгә кадәр дәвам итәчәк,** шуңа да сәләтегезне күрсәтергә ашыгыгыз. Конкурс нәтиҗәләре буенча төрле чаралар планлаштырыла. Әйтик, җирле үзешчән авторлар иҗатыннан төзелгән концерт, рәсемнәр күргәзмәсе үткәрү урынлы булыр иде дибез. Ә иң яхшы дип табылган шигырьләрне район газетасына тәкъдим итәргә уйлыйбыз.

Көчегезне сынап карарга беркайчан да соң түгел, талантлар, хәбәр бирегез. Район мәдәният бүлеге, мәдәният йорты сезне куанып каршы алачак.

*Ничек яшисең, кеше?*

# ЯЗМЫШ СЫНАВЫНА СЫГЫЛМАГАН

***Яктылыкның әсәре дә булмаган кап - кара чоңгыл. Нигә дип караңгыда ята соң әле бу? Тизрәк бу шомлы сөремнән котыласы иде. Ул караңгылык пәрдәсен аерырыга теләгәндәй кулларын һавага күтәрде, җайсыз, ипсез хәрәкәттән соң бармаклары күзләренә тиеп китте. Чү, нишләп аларда бәйләү бар соң? Нәрсә булды аңа? .. Аһ, димәк?.. Сыкраулы ыңгырашу иң тирәннән, егетнең күкрәк түреннән сыгылып чыкты да янәшәдәгеләрне сискәндереп куйды. Исенә төште, барысы да хәтерендә яңарды Володяның. Вишневая Поляна урманы, биек, биек агачлар, трактор! .. Әйе, әйе, трактор! .. Кинәт коточкыч чытырдау, машина улавы, кычкырган тавышлар аның бөтен башын чолгап алгандай булды. ... Ул куллары белән башына ябышты, бармак-лары янә күзләренә тиде. Күзләре, дөньяга яктылык бөркеп, сөенеп - сөенеп бага торган зәңгәр күзләре марля бәйләм астында иделәр.***

Володяның 99 нчы СПТУны тәмамлап, АВС категорияле шоферлык таныклыгы алырга өлгергән, 1 - 2 айдан хәрби хезмәткә китәргә әзерләнеп зур хыяллар белән яшәгән көннәрендә килде шундый фаҗига. Караңгылык чорнап алган яңа халәт аның өчен куркыныч, егет чарасызлыктан гаҗиз иде. Бөтен хыяллары чәлпәрәмә килде, алар урынына озын, ялыктыргыч шифаханә юллары башланды. Володяны башта ике тапкыр Мәскәүгә, Федоров клиникасына алып бардылар, аннан Санкт - Петербургтагы хәрби - медицина академиясе каршындагы клиниканың нейрохирургия бүлегендә өч тапкыр дәвалау узды. Бары шуннан соң гына егет яктылыкны шәйләрлек хәлгә килде, күз күреме 0,04 процент тәшкил итә башлады.

Яңа халәт авыр, бик авыр иде Володя өчен. Көч - куәт ташып торган яшь, энергияле, яшь җан канаты җәрәхәтләнгән кошчыкны хәтерләтә иде: талпына, кагына, ә очып китә алмый. Әмма тик тору да аның өчен җәза иде. 1995 елның гыйнвар ахырына Владимир Малинин Бөтенроссия сукырлар җәмгыяте линиясе буенча Мәскәү өлкәсе Волоколамск шәһәренә сукырларны реабилитацияләү һәм профессиональ хәзерләү институтына укырга китте. Күрмәүчеләр өчен нигездә ориентлашу, өй эшләре, Брайль системасын өйрәнүне эченә алган 2 айдан артыклык курсларны ул гел 5ле билгеләренә генә тәмамлап кайтты. Ул чакта ук тал чыбыгыннан кәрзиннәр үрү түгәрәгенә йөрде, бу эшнең нигезләрен үзләштерде. Ә 1996 елда инде шул ук институтта тал чыбыгыннан үрү белгечлеге буенча һөнәргә өйрәнү курсларында булды. Өч имтиханны да «бик яхшы» билгеләренә тапшырып, аннан «Тал чыбыгыннан үрү мастеры» дигән белгечлек алды.

Әмма ел Малининнар өчен яңа сынау әзерләгән икән әле - этиләре Виктор фаҗигале төстә һәлак булды. Ятим калган гаилә, йорт уртасында хуҗасыз калган иске «Москвич» машинасы яңа бер әрнү белән Володяның йөрәген телгәләде. Ул, Владимир калырга тиеш иде бит хәзер йорт башы булып. Типсә тимер өзәрлек егет машинасын да йөртергә, йорт - җирне дә карап - каккалап торырга тиеш иде. Әмма бу хәлендә гаиләгә инди ярдәмче инде ул? Эче пошкан көннәрнең берсендә, декабрь башларында Володя кулына тал чыбыклары алды. Аларны әйбәтләп чистартты, пешекләде дә әкрен генә кәрзин үрергә кереште. Аның күз алдында кәрзиннең бизәкләре, әзер рәвеше бар инде, бары аны гамәлгә ашырасы гына калды. Әмма бу бик тә җиңел эш түгел шул! Кәрзиннең һәр бизәген, пропорциясен бармакларың белән генә кармалап чамаларга туры килгәндә - бигрәк тә. Киеренкелекне сизгәндәй чыбык та сынып куя.



Андый чакта Володя кәефсезләнеп байтак вакыт кәрзинне кулына алмыйча йөри. Әмма ахыр чиктә тал чыбыгы егеткә тулысынча буйсына! Егет кичә генә елга буйларында, чокыр янәшәләрендә күзгә ташланмыйча тырпаеп үсеп утырган шыксыз чыбыклардан яңадан яңа бизәкләр тудыра. Менә бусы - хуҗалык кирәк - яраклары өчен тупас кәрзин. Бусы инде гөмбәгә йөрергә уңайлы бизәкле тырыс. Бу декоратив кәрзин чәчәкләр куярга матур. Ә менә бусы, сырлап үргәне - ипи савыты. Бу башлаганын урындык ясарга дип тора. Володя көннән - көн бармакларының җитезрәк хәрәкәт итүен тоеп шатлана, бизәкләрнең дә өр - яңалары, күзне җәлеп итә торганнары туып тора. Кәрзиннәргә ихтыяҗ туа. Декабрьдә генә Володя район хакимияте өчен берничә дистә кәрзин үреп бирде. Хәзер бу матурлыкны күргән, иясен белгән кешеләр аны Малининнарның өенә килеп алалар. Егет шулай үзенә шөгыль тапты. Әмма буйсынмас рухы моның белән генә канәгатьләнеп калмаска җыена Володяның. Киләсе сентябрьдә ул шул ук сукырлар җәмгыяте линиясе буенча Кисловодскида оештырылган массажистлар мәктәбенә имтихан тотарга җыена. Зиһене әйбәт, башы якты, куллары көчле аның. Аларга эшсез - хәрәкәтсез катарга, тупасланырга ирек бирмисе иде.

Норлатның Московская урамындагы 29 йортта яшәүче яшь Владимир Малинин шулай әле дә хыяллар, өметләр белән яши. Егеткә, аның әнисе Валентина Алексеевна һәм сеңлесенә ары таба җиңел булыр дип әйтә алмыйбыз. Әмма язмыш сынавына сыгылмаган, аңа каршы торырга ихтыяр көче таба алган Володя һичшиксез югалып калмас. Без моңа ышанабыз, шуны телибез, Володя!

**С.ХӘЙРУЛЛИНА.**

**Рәсемдә: Владимир Малинин.**

## Мәгариф яңалыклары

### Күршеләр октябрьлеләр тәҗрибәсен өйрәнәләр

Төрле район мәгариф бүлекләре хезмәткәрләре, педагогларының бер - берләренә ярдәм итешеп, тәҗрибә уртаклашып эшләүләре күптәннән гадәттә инде. Узган чәршәмбедә безнең районга Яңа Чишмә районыннан визит ясаган бер төркем педагогларны да бирегә шул максат китерде. Районның мәгариф бүлеге мөдире Ә.Х.Хөснетдинов җитәкчелегендәге педагоглар безнең районның икенче рус - татар мәктәп - гимназиясендә, Каравыл Тавы урта мәктәбендә, «Әкият» мәктәп - балалар бакчасы учреждениесендә булып, белем бирү учреждениеләрендә укыту - тәрбия процессының куелышын җентекләп өйрәнделәр, документлар белән таныштылар. Яңа чишмәлеләр районыбыз педагогларының эшен югары бәяләделәр, биредән үзләре өчен күп нәрсә алуларын ассызыкладылар.

### Фәнни - гамәли семинар

«Яңа педагогик технологияләр» - узган җомгада район мәгариф бүлегендә үткән фәнни - гамәли семинар шулай дип аталды. Анда райондагы инновацион белем бирү учреждениеләре җитәкчеләре, педагоглар катнашты.

Семинарда катнашучылар аның беренче өлешендә гимназия тибындагы «Родничок» балалар бакчасында, шәһәрнең икенче һәм дүртенче рус - татар мәктәп - гимназияләрендә, укыту - тәрбия комплексы булган «Камыр батыр» мәктәп - балалар бакчасы учреждениесе, Иске Чаллы агролицее, Киекле татар гимназиясендә инновацион учреждениеләр педагоглары үткәргән дәресләрдә булдылар, класстан һәм мәктәптән тыш чараларны карадылар, тәҗрибә уртаклаштылар. Семинарның теоретик өлеше шәһәрнең дүртенче рус - татар мәктәп - гимназиясендә үтте. Анда Казан дәүләт педагогия университеты галимнәре - педагогика кафедрасы мөдире, профессор, педагогика фәннәре докторы, академик Г.Г.Габдуллин һәм психология кафедрасыннан психология фәннәре кандидаты А.Ф.Корнеенко да катнаштылар.

# ЭТНЕҢ БЕТӘСЕ ЮК АХРЫ...

***Норлатның кайсы гына ягына барып чыксаң да, этләр өеренә тап буласың. Ул хуҗасыз этләрне ату белән шөгыльләнәләрме икән? Югыйсә өйдән чыгарга куркыныч бит.***

**А.Николаева.**
**Норлат шәһәре.**

Норлатлыларның күбесе бу аптыраулы .сорауны бирәдер, мөгаен, чөнки район санитария - эпидемиология күзәтчелеге һәм эчке эшләр бүлеге мәгълүматларына караганда, этләр һөҗүменә юлыгучылар елдан - ел арта бара. Шулай да бу хакта тәфсиллерәк мәгълүмат алу максатында без санэпидкүзәтчелегенә һәм күптармаклы производство предприятиесенә мөрәҗәгать иттек.

**Т.СОРЕНКОВА, санэпидкүзәтчелек үзәгенең эпидемиология бүлеге мөдире.**

-Төрле хайваннар тешләве нәтиҗәсендә барлыкка килә торган котыру чире бүгенге көндә актуаль проблема булып тора. Статистика буенча бу каты йогышлы авырудан дөньяда ел саен 50 меңнән артык кеше һәлак була. Йогышлы вирусны төлке, бүре кебек урман хайваннары, безнең тирәдәгеләр - күселәр һәм этләр йөртә. Шәһәрдә иясез этләр артуы нәкъ шул кеше өчен үлем алып килә торган яман чир килеп чыгу куркынычы белән яный да. Соңгы 5 елда эт тешләү очраклары артканнан - арта бара. 1995 елда 199 кеше теркәлгән булса, үткән елда бу сан 7 кешегә арткан. Шул исәптән 82се 14 яше тулмаган балалар. Этләрдән җәрәхәт алучыларның күп өлеше (131 очрак) шәһәр халкына төшә. Барлыгы 42 кеше район үзәк һәм участок больницаларына озатылды, 115 кешегә прививка ясалды. Быелның башыннан гына да эт тешләү турында 5 ашыгыч хәбәр булды. Һәр шундый очрак яман чир йоктыру куркынычы белән яный. Аны булдырмас өчен бөтен яктан профилактика чаралары күрү мөһим: иң элек халыкның үз этләрен урамга, өеннән ерак урыннарга чыгармавына ирешү зарур. Йортын, милкен саклау максатында көчек алган һәркем шуны истә тотсын иде, эт кешенең дусты гына булып калмыйча, кешедә дә аңа карата мәрхәмәтле караш сүнмәсен иде. Нәкъ менә шундый ташланган, иясез этләр чүплек базларында, подвалларда яшәп һәм тукланып төрле зарарлы авырулар йоктыралар да.

**Газета укучыбыз соравына МППның этләр ату буенча җаваплы кешесе Н.МИРЗАНОВ җавап бирә.**

- Безнең предприятиедә этләр ату буенча махсус бригада эшли. 1996 нчы елда 249 сукбай эт атылды. Бу максатлар өчен МПП исәбеннән 2522000 сум акча тотылды.

Быел мәктәп укучыларының кышкы каникулы чорында саклык йөзеннән эт атуларны туктатып торырга туры килде. Бүгенгесе көндә һәр көнне диярлек кичке сәгать 9дан соң аучылар эшкә чыга. Безнең белән бергә район эчке эшләр бүлеге хезмәткәре дә була. Шулай, быел дүрт тапкыр чыгуда 40 этне аттык. Бу мәсьәлә белән чакырулар да еш булып тора, без бу очракта кичектермичә барырга тырышабыз. Шунысы кызганыч: күп кенә хуҗалар эт асрыйлар, әмма үзләре аны асрау кагыйдәләрен я белмиләр, я белеп тә үтәмиләр. Капкада «Йортта усал эт бар» дигән таблица элеп кую бик сирәк кешедә күзәтелә. Бәйдә торып усалланган этләрен ирекгә ычкындырып җибәргәндә аның кемнедер тешләве яки куркытуы хакында да уйлап мәшәкатьләнмиләр. Тик соңыннан шул сәбәпле этләре атылса гауга кузгаталар. Эт асраучы хуҗаларны тагын бер кат кисәтәсе килә: этегез атылуын теләмәсәгез, аны бәйдән ычкындырмагыз.

# Укучыларыбыз иҗаты

***Алдан хәбәр ителгән буенча 16 гыйнвар көнне район газетасы редакциясенә әдәби түгәрәк утырышында катнашырга бер төркем шигырь сөючеләр килде. Бүген газетабызда әдәби түгәрәк әгъзаларының шигъри күчтәнәчләрен сезнең игътибарга тәкъдим итәбез.***

## Җырла, Илфат

**(Бер шигырь тарихы )**

Туган җиремне бик
Сагындым дускаем,
- Туган җир бәхет,- дип
Сайрый бит кошкаем...

дип, өздереп, күңелләрне кузгатырлык итеп җырлый Илфат. Җыр Җиңү бәйрәменә багышланган концертта авыл халкы алдында яңгырый. Шушы моң туган җирләреннән читтә яшәүчеләрнең күңелләрендәге сагыну хисләрен мөлдерәмә ясап, күзләреннән яшь итеп саркытып чыгара. Бу моң күптән түгел генә Илфатның әнисен һәм берсеннән - берсе кечкенә өч баласын ятим итеп вакытсыз үлеп киткән этиләрен югалту кайгысын йөрәк аша кабат кичертеп үзәкләрне өзә.

«Кошкаем» дигән шигыремне мәктәптә ел саен уздырыла торган «Кошлар көне»нә багышлап яздым да, Илфатка ятларга бирдем. Көннәрдән бер көнне «Апа, бу шигырьне җыр итеп җырлап та була бит»- дип, минем янымa килгән бу. Шунда ук җырлап та күрсәтте. Яшермим, күңелем тулды. Кичәдә инде бу җырны алар икәүләп - җиденче класс укучысы Әбделвәлиев Илфат гармунда уйнап, ә Зәйдуллин Илфат җырлап башкардылар.

«Кошкаем» җырын алар район мәдәният йортында үткәрелгән Тукай кичәсенә дә алып килделәр. Залда бер буш урын юк, зур сәхнә, шул сәхнәдә бишенче класс укучысы кечкенә генә буйлы Илфат, ә тавышы, моңы... Аннан әсәрләнмәгән кеше калмагандыр бу кичәдә.

Җәен Илфатның әнисе Наилә өч баласын да ияртеп Ташкентка, кыз туганы янына күчеп киткән диделәр.

Илфат, Илфат... Шаян да, шук та, җитез дә, мөлдерәмә кара күзле ут малай күңелемдә һаман «Кошкаем» җырын җырлый иде. Онытa алырмы ул үзенең туган авылын, Тарлау чишмәләрен, Тигәнәш аланнарын, биек багана башына менеп -этәч алып төшкән сабан туйларын, җилдереп коштай очкан тулпар атларын, эти - әнисе нигезе калган туган якларын?!

- Наилә кайткан, балаларының авылны сагынуларына түзә алмыйча,- дигән хәбәр көтмәгәндә килеп иреште.

Мәктәптә Илфат яныма килүгә, мин аңа:

- Илфат, менә бу шигырь синә, җырла, яме! - дидем һәм шушы шигыремне бирдем.

Кайттым сиңа, ямьле Киеклем,
Газиз ягым, саумы, сөеклем,
Хәтфә келәм җәйгән урамым
Яланаяк кат - кат урадым.

Колач җәеп ачып ишеген,
Әй авылым - яшел бишегем,
Белдем синең каршы аласың
Адашып ла йөргән баласын.

Җилдәй җитез акбүз аткаем
Каршы килә чайкап башкаен,
Алмалыкта үскән кушкаен
- Сагындым,-
дип сине, дускаем.

Талларым да сөеп карыйлар,
Җилләр назлап чәчем
тарыйлар,
Чирмешәндә йөзәм кочаклап -
Дулкыннары ала колачлап.

Туган ягым, синнән еракта
Сагыш тулы иде йөрәктә,
Яшәдем мин сине сагынып,
Яралы кош кебек кагынып.

Кайда булсам, кайда йөрсәм дә
Күз алдыма сине китерәм,
Күңелемнән шуны кичердем:
Туган җирдә бәхет, офык киң,
Кешеләре гүзәл, гөлгә тиң.

Илфат шигырьне тыңлады, ризалашып башын какты да йөгереп китеп барды. Ул инде сагыну - юксынудан боеккан китек күңелле адашкан җан түгел иде. Ул - үз илендә, үз җирендә, шуңа кәефе дә көр, күңеле дә күтәренке, үзе дә бәхетле.

Җырла, Илфат. Синең талларың туган ягыңда. Матур җырлар җырлап, тәүфыйклы, бәхетле булып үс!

**Р.МӘСЛӘХОВА.**

---

**Тәзкирә АЛЯКИМОВА.**

### *Бисмиллаһи диеп әйтсәк*

Бисмиллаһи - диеп әйтсәк,
Аллаһыны истә тотып.
Ихлас белән әгәр әйтсәк,
Шайтан качар бездән куркып.

Бисмиллаһи - диеп әйтик,
Эшләребез башында.
Йөзләребез якты булыр
Аллаһының каршында.

Бисмиллаһи әйткәннәрнең
Йөзләрендә нур булыр.
Аллаһыны онытканнар
Дөнья - ахирәт хур булыр.

Бисмиллаһи дип әйтәбез
Кальбебезгә нур тулсын.
Җир йөзендә бар кеше дә
Изгелеккә омтылсын.

# Белдерүләр Реклама


**Октябрь урман хуҗалыгы сатып алучының заявкасы буенча өйгә китереп бирү шарты белән үзенең түбәндәге продукцияләрен тәкъдим итә:**

**төзелешкә яраклы агач - куб.метрын 120 мең сумнан;**
**утын - 56700 сумнан;**
**ярган агач материалы - 250 мең сумнан;**
**рәшәткәлек - 320 мең сумнан;**
**шулай ук «Идел» газ плитәләре - 625 мең сум.**

**Түбәндәге эшләнмәләргә заказлар кабул ителә:**
**ылыслы агачтан тәрәзә борыслары һәм рамнары - квадрат метры 56 мең сум;**
**такта ишекләр - 500 - 700 мең сум;**
**стандарт ишекләр - 450 мең сум;**
**ишек борыслары - 100 мең сум;**
**ылыслы агачтан метрлы әйберләр:**
**ылыслы агачтан борыслар - метры 4 мең сум,**
**сырлы һәм гади плинтуслар -**
**ылыслы агачтан метры - 3 мең сум,**
**яфраклы агачтан - 1 мең сум,**
**штапиклар -**
**ылыслы агачтан метры - 100 сум,**
**яфраклы агачтан - 50 сум,**
**тышлау рейкасы -**
**ылыслы агачтан - бер куб. метры - 750 мең сум (кипкәне) һәм 600 мең сум (кипмәгәне),**
**яфраклы агачтан - 550 мең сум һәм 400 мең сум,**
**идән рейкасы - ылыслы агачтан - куб.метры 850 мең сум,**
**яфраклы агачтан - 630 мең сум.**

**Октябрь районы пенсионерларына агач продукциясен пенсия хисабына бирергә дә була.**

**Утын, ярган агач материалы, төзелешкә яраклы агач һәм газ плитәләре заявка кергәннән соң 5 көн эчендә китереп бирелә. Метрлы әйберләрне илтеп бирү - аларның кайчан эшләнүенә карап. Илткән өчен ара ераклыгыннан чыгып 50 мең сумнан алып 80 мең сумга кадәр түлисе.**

Заявкалар 2 - 26 - 58, 2 - 10 - 48, 38 - 2 - 88 телефоннары буенча иртәнге 8 дән кичке 4 кә кадәр кабул ителә.

**Норлат геофизик эшләр идарәсе арзан бәя белән түбәндәге әйберләр сата (бартер алмашуы да мөмкин):**

**төрле амперметрлар - 30 данә,**
**«Комфорт» конвекторлары (су батареялары) - 24 данә,**
**өч юнәлешле кран - 40 данә,**
**су исәпләгечләр - 10 данә,**
**унитаз өслеге - 150 данә,**
**шпал аслыклары (шпалоподбойка) - 6 данә,**
**ПЕ - 1 автоматикасы щитлары - 5 данә,**
**К - 700гә резина - 4 данә,**
**электрон стена сәгатьләре - 5 данә.**

Адрес: Норлат шәһәре, Советская ур., 138, тел.: 5 - 13 - 86, 5 - 18 - 96.

**Торак һәм башка объектлар төзү белән шөгыльләнүче барлык предприятиеләр, оешмалар, учреждениеләр игътибарына!**

**Район элемтә узелы телефонлаштыру, радиоалаштыру һәм почта ящиклары кую эшләре техник шартлар буенча гына уздырылуы турында кисәтә.**

Мөрәҗәгать итү өчен тел.: 2 - 20 - 60, 2 - 22 - 22.

**Узел администрациясе.**

**«Норлатгаз» эксплуатация - производство участогы челтәр газыннан файдаланучыларның барысыннан да файдаланылган газ өчен түләүне саклык банкы аша үткәрүләрен сорый. Башка оешмалар, торак - коммуналь бүлекләре һәм хуҗалыклары (ЖКО, ЖКХ) аркылы түләүләр 1 февральдән соң исәпкә алынмаячак.**

Тел.: 2 - 28 - 58, 2 - 27 - 28.

**Шәһәр газ хуҗалыгы администрациясе.**

***Идел Буе региональ наркология үзәге***

*Алкогольгә бәйлелектән һәм тәмәке тартудан бер сеанста кодлаштыру.*

***Табиб М.Б.Багрянцев.***

***Бездә генә!***

**Тулы анонимлык. Индивидуаль якын килү. Дәвалау барышында пациентның туганнарына да катнашырга рөхсәт ителә. Белешмә бирелә. Консультация, әңгәмә, кодлаштырудан соң күзәтү һәм ярдәм - бушлай!**

**Язылу һәм әңгәмә дәвалау көнне, җомга көннәрендә, 14, 28 февральдә көндезге сәгать 2дә район мәдәният йорты бинасында уздырыла.**

РФ сәламәтлек саклау министрлыгыннан 1995 елның 16 гыйнварында бирелгән № 00164 - 30 лицензия.

***«Связист» кибетендә Германиядә чыккан вилюр чүәкләрнең барлык үлчәмнәре дә, киң ассортиментта канцелярия товарлары бар.***

Безнең кибеткә рәхим итегез.

***Сатабыз***



**«Алмалык»та дача, мунчасы, коесы, үсентеләре бар.** Адрес: Советская ур., 189 - 36.

***

**Ат дугасы (60 данә) һәм ГАЗ - 69га рессорлар.** Каравыл Тавы авылында Майоровка мөрәҗәгать итәргә.

***

**Чистарту корылмалары тирәсендә гараж.** Адрес: К.Маркс урамы, 4 - 23.

***

**1983 елгы ВАЗ - 2105.** Адрес: Синдряков ур., 47, тел.: 2 - 23 - 42.

***

**Италиядә чыккан яңа автомат кер юу машинасы.** Тел.: 2 - 27 - 20.

***

**5 х 4 метрлы төрткесез бура.** Тел.: 4 - 13 - 74.

***

**Каралтылары белән торак йорт.** Чулпан авылында Солтан Хөснуллинга мөрәҗәгать итәргә.

***

**1991 елгы ВАЗ - 21063, 5 х 5 метрлы бура**. Тел.: 5 - 27 - 20 (кичке 4тән соң).

***

**1994 елгы «Москвич - 2141», «Таурас» телевизоры.** Тел.: 2 - 27 - 99 (кичке 6 дан соң).

***Акцияләр сатып алабыз***

**«Татнефть» АҖнең Б категорияле,**
**«Сургутнефтегаз» АҖ,**
**«ЛУКойл НК» АҖ,**
**«ЛУКойл - Лангепаснефтегаз» АҖ,**
**«ЛУКойл - Урайнефтегаз» АҖ,**
**«ЛУКойл - Когалымнефтегаз» АҖ,**
**«Ноябрьскнефтегаз» АҖ,**
**«Газпром» РАҖ акцияләрен.**

Безнең адрес: «Сервистехинвест» ЧИФ. К.Маркс ур., 12 (ишегe яннан). Тел.: 2 - 19 -30.


## Газета - *укучы* - газета

# ЙОРТКА КЕМ ХУҖА?

Алло, редакцияме бу? Сезгә Дружба урамының 78 нче йортыннан шалтыраталар әле. Төшке ашка кайтып керсәм җылылык батареяларыннан су агып ята. Ашыгыч рәвештә слесарь кирәк булгач, МППга шалтыраттым, ә алар НГДУ ЖКХсыннан ярдәм сорарга киңәш иттеләр. Аларның номерын җыйган идем, җылылык һәм коммуналь хезмәтләр өчен акчаны кая түлисез, шунда мөрәҗәгать итегез, диделәр. Эчемнән генә алар белән килешеп, тагын МППга шалтыратам. Икенче кабат шалтыратуым ошамагандыр, күрәмсең, телефонны алган хезмәткәр трубканы куйды. Ә бит су һаман ага...

Без бу йортка былтыр көз күчтек. Күршеләрне әйтә алмыйм, әмма үзебез акчаны вакытында түләп барабыз. Шулай булгач, безгә кем ярдәм күрсәтергә тиеш икән соң? Анысын җитәкчеләр беләдер дип уйлыйбыз инде.

## *Төрлесеннән*

### Җир кисәтә

Нефть чыккан урында беренче җир селкенүне 1939 елда сизәләр. Американың Уллмингтон нефть ятмасыннан ерак урнашмаган Лос - Анджелес, Лонг - Бич шәһәрендә җир селкенә һәм утыра башлый/

1971 елда иске нефть ятмаларыннан 16 чакрымда урнашкан Грозный шәһәрендә җир тетрәү 7 баллга җитә.

1989 елда Татарстанның Менделеевск шәһәре янындагы җир тетрәү 6 балл күрсәтте.

Белгечләрнең әйтүенчә, нефть чыгару белән җир тетрәү арасында туры бәйлелек бар.

### Даны - ил өчен, доллар спортчы өчен

1998 елгы кышкы Олимпия уеннарында җиңгән Татарстан спортчысына 500000 АКШ доллары биреләчәк. Көмеш медаль иясенә - 30, ә бронза өчен 20 мең шундый ук доллар тапшырылачак. Әлеге кызыксындыру тренерларга да кагыла: аларга спортчыларга түләнгән сумманың яртысы тиеш.


БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

**Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

**"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы,19.**

**Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар һәм җәмагать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, җаваплы сәркәтип - 2-18-67, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.**

***Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.***

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2047 данә. Заказ N 5152.